КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 декабрь г.Казань № 1263

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2010 ел, 10 сентябрь, 7269 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 ноябрь, 961 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның өченче абзацында «Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) җыелма реестры» (алга таба – Федераль җыелма реестр)» сүзләрен «Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» (алга таба – Федераль реестр)» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктта «җыелма» сүзен төшереп калдырырга;

4 нче пунктта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацта «санлы» сүзен төшереп калдырырга;

10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Бу карарның үтәлешен тиешерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче; 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; 2016 ел, 6 август, 533 нче; 2016 ел, 12 декабрь, 918 нче; 2017 ел, 21 март, 168 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 649 нчы; 2018 ел, 1 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1093 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче; 2019 ел, 22 ноябрь, 1065 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4.1 нче пунктның 4.1.10 нчы пунктчасындагы өченче абзацында «Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) җыелма реестры» сүзләрен «Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин